# КАРАР

## Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Якушкино авыл җирлеге Салдакай авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«30» март 2021 № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2021 елның 30 мартында узган халык җыены нәтиҗәләре белән түбәндәге сорау буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Якушкино авыл җирлегенең Салдакай торак пунктында 2020 елның 13 ноябрендә кабул ителгән 5 номерлы элек расланган гражданнар җыены нәтиҗәләре турында карарга һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Якушкино авыл җирлегенең Салдакай авылында халык җыенының 13.11.2020 ел, № 6 карарына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү белән килешәсезме?:

Якушкино авыл җирлеге Салдакай авылы территориясендә теркәлгән һәм яшәүче 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннары, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары һәм уку йортларында көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан кала, балигъ булган һәр кешедән, 2021 елда 1000 сум күләмендә җыелган үзара салымны югарыда күрсәтелгән карарлар белән расланган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерелергә мөмкин булган эшләр исемлеген түбәндәгечә бәян итәргә:

Салдакай авылының Үзәк урамында ял итү зонасын булдыру һәм төзекләндерү;

Салдакай авылындагы К. Маркс урамы буенча күлне чистарту, күл ярларын ныгыту һәм төзекләндерү;

Салдакай авылы чикләрендә авыл эчендәге юлларны карап тоту һәм ремонтлау, шул исәптән сезонлы карап тоту;

Салдакай авылында урам утларын ясау һәм карап тоту».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

җыенда катнашучы сайлау хокукына ия булган гражданнар исемлегенә 284 кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә 150 кеше катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 147 кеше тавыш бирде;

«ЮК» позициясе өчен җыенның 3 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Якушкино авыл җирлеге Салдакай авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Якушкино авыл җирлегенең Салдакай торак пунктында 2020 елның 13 ноябрендә кабул ителгән 5 номерлы элек расланган гражданнар җыены нәтиҗәләре турында карарга һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Якушкино авыл җирлегенең Салдакай авылында халык җыенының 13.11.2020 ел, № 6 карарына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү белән килешәсезме?:

Якушкино авыл җирлеге Салдакай авылы территориясендә теркәлгән һәм яшәүче 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннары, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары һәм уку йортларында көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан кала, балигъ булган һәр кешедән, 2021 елда 1000 сум күләмендә җыелган үзара салымны югарыда күрсәтелгән карарлар белән расланган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерелергә мөмкин булган эшләр исемлеген түбәндәгечә бәян итәргә:

Салдакай авылының Үзәк урамында ял итү зонасын булдыру һәм төзекләндерү;

Салдакай авылындагы К. Маркс урамы буенча күлне чистарту, күл ярларын ныгыту һәм төзекләндерү;

Салдакай авылы чикләрендә авыл эчендәге юлларны карап тоту һәм ремонтлау, шул исәптән сезонлы карап тоту;

Салдакай авылында урам утларын ясау һәм карап тоту» мәсьәләсе буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Якушкино авыл җирлеге Салдакай авылы мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Якушкино авыл җирлеге тарафыннан кабул ителгән әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: Х.Х.Хәмидуллин

Якушкино авыл җирлеге башлыгы Х.Х.Хәмидуллин